| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Менделеевский муниципальный район<br>Совет Мунайкинского сельского поселения | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Монай авыл жирлеге Советы |

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2021 елның 12 апрелennнән N 27

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
"Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә
халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын)
оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2018 елның 5 сентябрендәге 79 номерлы Монай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 12 статьяның 3 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.»
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" киләсе веб-адрес буенча бас-тырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә киләсе веб-адрес буенча урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan.ru

Монай авыл җирлеге
Советы рәисе Р.М.Кириллов